КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь

г.Казань

№ 1511

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 август, 785 нче карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәт күрсәтүләр күләмнәренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында» 2021 ел, 31 август, 785 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 июнь, 572 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы

оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарга, аларны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 август, 785 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 30 декабрь, 1511 нче
карары редакциясендә)

2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалар, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының мәгариф оешмалары һәм спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәт күрсәтүләр күләмнәре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Саны, кеше | |
|---|---|---|
| | 01.01.2022 дән 31.05.2022 гә кадәр | 01.06.2022 дән 31.12.2022 гә кадәр |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 15 330 | 19 622 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 484 | 1 540 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 9 610 | 53 889 |
| Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 925 | 3 611 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 31 397 | 72 876 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 120 | 4 110 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 4 951 | 29 789 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 457 | 1 824 |